Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлегенең
Монай авылында гражданнар җыены

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

28.11.2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 18 ноябрендәге 3 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында" карары нигезендә, Монай авыл җирлегенең Монай авылы гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, свода катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары тыш, 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

«1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төзүчеләр, Төньяк, Йолдыз, Ленин урамнарына вак таш җәю, Төзүчеләр, Монтажчылар урамындагы юл өслегенең чокырларын ремонтлау, транспорт хезмәтләре күрсәтү (автогрейдер хезмәтләре күрсәтү)".

2. Әлеге карарны Монай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Монай авыл җирлеге" бүлегендә (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

Халык җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге башлыгы ______________ Р.М.Кириллов
(имза) (имзаның аңлатмасы)